**«Тамчы – ШОУ»**
**Интеллектуаль уены**
(Класстан тыш чара)

Максат: Укучыларда фән белән кызыксынуны арттыру, аларда бер-берсенә карата иптәшлек- дуслык хисләре тәрбияләү. Бер-береңә игътибар, яхшы мөнәсәбәт булдыру.

**Туган җирем минем – Татарстан**
**Илгә байлык өсти кырларың.**
**Уңышларың якты табыннарга**
**Алып килә шатлык җырларын.**
**Кулың тисә, туфрак алтын була**
**Тирең тамса, шыта гөл булып.**
**Күкрәгеңнән чыккан кайнар хисләр**
**Яңгырыйлар матур җыр булып.**
**Җиргә бассам, арта егәрлегем,**
**Күккә менсәм, иркен тын алам.**
**Туган җирем минем – газиз җирем**
**Мин бәхетле синең бер балаң.**

Бүгенге кичәбез мәктәбебез тарихына якты истәлек, якты сәхифә булып язылыр. 8- 11 класс укучылары катнашында “Тамчы - ШОУ” интеллектуаль уенын башлыйбыз.
Бүгенге бәйгене бәяләп бару өчен жюри составын тәкъдим итәм.
/Килгән кунаклар арасыннан жюри сайлап куела/

Бүгенге уен берничә турда узачак. Уенның шартлары белән һәр тур алдыннан таныштырылыр.
**1 нче турны башлыйбыз – Сәламләү.**
Командалар үзләре белән таныштыралар, исемнәрен һәм девизларын атыйлар.
/Беренче команда “Эрудит”, икенче команда “Интеллект”/.

**2 нче тур: “Разминка”. 1 минут вакыт эчендә төрле сорауларга җавап бирү.**
1 нче Эрудит командасы башлый.
Сораулар:
1. *Нәрсәне йомык күз белән дә күреп була? (төш)*
2. *Кытайдан Европага үтүче урта гасыр сәүдә юлы. (Бөек ефәк юлы)*
3. *Кычыткканда нинди кислота кулны “чага”? (кырмыска кислотасы)*
4. *Ятса – таш, якса – утын. (ташкүмер)*
5. *Африка янындагы иң зур утрау. (мадагаскар)*
6. *Нинди агач Россиянең символы булып тора? (каен)*
7. *Бензолның формуласын әйтегез (С6Н6)*
8. *“Көн” белән “Төн” арасында нәрсә бар? (“ө” хәрефе)*
9. *Баллы төш (чәкчәк).*
10. *Почмакны урталай бүлүче сызык (биссектриса)*
11. *Волейбол уйнаучы 2 командада барысы ничә уенчы? (12)*
12. *СИ системасында үткән юлны үлчәү берәмлеге (метр)*
13. *Беренче космонавтның фамилиясе (Гагарин)*
14. *1 сәгатьтә ничә минут (60)*
15. *Әтәч бер аягында басып торганда 3 кг була, икенче аягында торганда күпме булыр? (3 кг)*
16. *Мәктәптәге иң югары билге (5 ле)*

17. *Банан үсемлеге агачмы? (юк)*
18. *Йомырканың чи ме, пешкәнме икәнен ватып карамыйча ничек белеп була? (әйләндереп)*
19. *Катетларның квадратлары суммасы нәрсәгә тигез? (гипотенузаның квадратына)*
20. *Таблица төзегән бөек химик (Менделеев)*
21. *Иң яраткан фәнегез*
22. *Беренче класста ничә укучы укый (10)*
23. *Мәктәп директорының туган авылы (Татар Суыксы)*
24. *Ишектән кергәч таптыйбыз, үзен матур дип мактыйбыз (идән келәме)*

"Интеллект" командасына сораулар:

1. *Кара мәче нинди ишектән керә? (ачык)*
2. *"Әбидә" – юк, "бабайда" – бар ("а", "ә" хәрефе)*
3. *Ике боҗралы кисү җайланмасы ( кайчы)*
4. *1 сәгатьтә ничә секунд? (3600)*
5. *Төш тирәли хәрәкәт итүче тискәре корылма (электрон)*
6. *Кайсысы авыррак: 1 кг мамыкмы, әллә 1 кг тимерме? (тигез)*
7. *Җәен соры, кышын ак, аңа шулай яхшырак (куян)*
8. *Җир шарындагы иң озын елга (Нил)*
9. *Си системасында вакыт үлчәү берәмлеге (секунд)*
10. *Тавышсыз дип нинди хәрефләрне атыйбыз (ь – билгесе, ъ - билгесе)*
11. *Татарстанның узган елгы чемпион командасы (Рубин- футбол)*
12. *Гөмбә – үсемлекме? (юк)*
13. *Беренче хатын-кыз космонавт (Терешкова)*
14. *Термометр белән нинди физик зурлыкны үлчиләр? (температура)*
15. *Ашказаны сыекчасы составына нинди кислота керә (хлорид кислотасы)*
16. *Нинди кош оча алмый, ләкин бик оста чума һәм йөзә ала? (пингвин)*
17. *Теш эмаленә катылык һәм ак төс бирүче химик элемент, галоген (фтор)*
18. *Футбол тубы авырыракмы, әллә баскетболныкымы (баскетбол тубы)*
19. *Абага кайчан чәчәк ата? (чәчәк атмый)*
20. *Борынгы грек аллаларының патшасы (Зевс)*
21. *Евравидениедә 2 урынны алган татар кызы (Алсу)*
22. *Иң яраткан укытучыгыз*
23. *Икенче класста ничә укучы укый? (9)*
24. *Суда юынып алды, өсте коры калды. (каз, үрдәк)*

Музыкаль тәнәфес

**3 нче тур." Җавабын тап" конкурсы.**

Экранда төрле фәннәр буенча сораулар бирелгән. Һәр сорау катлаулылыгына карап баллар белән бәяләнә.

Фәннәр:
- *татар теле*
- *биология*
- *физика*
- *математика*

Татар теле өчен сораулар:

*2 балл: татар алфавитында ничә хәреф бар? (38)*
*3 балл: астына сызылган сүз нинди җөмлә кисәге булып килә?*
*<u>Сандугач дигән</u>, әй,асыл кош, гөлбакчада сайрый ояда. (аергыч)*
*4 балл: Боланың кайсысы сөйләм органы түгел?*
*Үпкә, бугаз, тын юлы, тавыш ярылары, бавыр, авыз куышлыгы, кече тел, ашказаны, тел, теш, иреннәр, борын / бавыр, ашказаны /*
*5 балл: Түбәндәге сыйфатлар нинди җөмлә кисәге булып килгәннәр?*
*Күңелле яшибез, матур җырлый, яхшы эшли, җиңел атлый, ямьсез кылана. (хәл)*

Биология өчен сораулар:
*2 балл: цитруслыларга нинди үсемлекләр керә? (апельсин, лимон, мандарин, грейпфрут)*
*3 балл: авыз куышлыгы гигиенасын сакламау нәтиҗәсендә килеп чыккан тешләрдәге авыру (кариес)*
*4 балл: Д витамины җитешмәгәндә була торган авыру (рахит)*
*5 балл: гемоглобин составына керә торган металл (тимер)*

Физика өчен сораулар:
*2 балл: ток зурлыгын үлчәү приборы /амперметр/*
*3балл: тимерне сулы савытка төшергәч аның тыгызлыгы үзгәрәме? /юк/*
*4 балл: кыяр тозлау нинди күренешкә нигезләнә? /диффузия/*
*5 балл: иң түбән температура /- 273/*

Математика өчен сораулар:
*2 балл: төнге каравылчы көндез үлсә, аңа пенсия түләнәме? /юк/*
*3 балл: параллепипедның ничә кабыргасы бар? /12/*
*4 балл: хәзер сәгать кичке 6. Тәүлекнең күпме өлеше үткән? / ¾ /*
*5 балл: иң төп һәм кечкенә геометрик фигураны атагыз /нокта/*

Концерт номеры.

**4 нче тур. Капитаннар ярышы.**
Мин сезгә халкыбыз мәкальләренең яртысын әйтәм, ә сез дәвам итегез.
1 нче командага:
1. *Хезмәт төбе – хәзинә;*
2. *Тырышлык –зурлык, ялкаулык – хурлык;*
3. *Сөйдергән дә тел, биздергән дә тел;*
4. *Күп торганга таянма, күп белгәнгә таян;*
5. *Эшләгәнең кешегә булса, өйрәнгәнең үзеңә булыр;*
6. *Ата- ананы тыңлаган – адәм булган, тыңламаган – әрәм булган;*
7. *Акыллы өйрәнер, ахмак өйрәтер;*
8. *Калган эшкә кар явар;*
9. *Кеше холкын күзәт, үзеңнекен төзәт;*
10. *Акыл яшьтә түгел, башта.*

2 нче командага:
1. *Тырыш бәхетне эшендә күрер,ялкау бәхетне төшендә күрер;*
2. *Алтын җирдә табыла, белем китаптан;*
3. *Бер яхшы эш мең яхшы сүздән артык;*

4. *Улның ояты атага, кызның ояты анага;*
5. *Ата- аналы- алтын канатлы;*
6. *Туры әйткән котылыр, алдап әйткән тотылыр;*
7. *Тату туганнар таштан койма койганнар;*
8. *Бауның озыны, сүзнең кыскасы яхшы;*
9. *Уңган кулда ут уйный;*
10. *Карама кешенең сүзенә,кара эшенә.*

Музыкаль тәнәфес.

**5 нче тур. Әлеге ярыш**
**“Белем баскычлары” дип атала.**
Баскычлардан өскә менәр өчен әлеге шакмакларда яшеренгән сорауларга дөрес җавап бирергә кирәк.

*Әдәбият баскычы. Габдулла Тукай яшәгән урыннарны дөрес тәртиптә урнаштырырга:*
*Кушлавыч, Сасна, Өчиле, Казан, Кырлай.*

*География баскычы. Татарстандагы елгаларны аларның республика буенча озынлыгы кими бару тәртибендә урнаштырыгыз:*
*Кама, Идел, Чулман, Агыйдел*

*Химия баскычы: матдәнең исеме белән бу матдә кергән неорганик кушылмаларның классы (төркеме) туры килүен билгеләгез*
*А) алюминий гидроксиды 1) нигез*
*Б) кальций карбонаты 2) урта тоз*
*В) натрий гидросульфаты 3) кислота оксиды*
*Г) хлор (VII) оксиды 4) әче тоз*
*5) амфотер гидроксид*

| *А* | *Б* | *В* | *Г* |
|---|---|---|---|
| | | | |

*Рус теле баскычы: бирелгән сүзләрдәге хаталарны төзәтегез*
*политэкономия, герцогиня, пощечина, вентиляция*
*адъютант, инъецировать*

/Концерт номеры/

**6 нчы тур. “Сурәтләрне таны” конкурсы.**

*Экранга билгеле бер вакыт эчендә танылган шәхесләрнең сурәтләре фотолары чыгачак. Сезгә аларны танырга кирәк.*

Жюри бәйгегә йомгак ясый торган арада укучыларыбыз һәм укытучыларыбыздан сезгә музыкаль бүләк.
/Концерт номерлары/

***Тыңла әле, бер моң ишетелә***
***Ул моңнар бит чыга йөрәктән***

***Шул ук моңнар язмышларны җиңеп***
***Яшәргә бит безне өйрәткән.***

***Тыңлыйк әле, таныш моңнар ага***
***Талгын сулар аккан шикелле.***
***Моң иясе, безгә таныш бугай***
***Үзе якын, үзе сөйкемле.***

***Җырлар – ул күңел көзгесе,***
***Җырлар – ул гүзәл бизәк.***
***Кадерен белеп тормышның***
***Җырлап яшәргә кирәк!***

***Бүлмәләргә сибелсен җыр,***
***Җырлардан күчсен җылы***
***Җырлар бит – бәхет билгесе***
***Җырлар бит – күңел нуры.***

*Шуның белән бүгенге ярышыбыз тәмам. Барыгызга да укуыгызда уңышлар телим. Бүгенге ярышта бик яхшы катнашкан һәм җиңү яулаган командасы алтын медальләр белән бүләкләнә.*
*Икенче призлы урында___командасы. Аларны да чын күңелдән тәбриклибез һәм көмеш медальләр тапшырабыз.*
*Игътибарыгыз өчен рәхмәт, киләсе бәйгеләргә кадәр сау булыгыз.*